ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода, 422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы, 422591

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.11.2020 №177

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Введенская Слобода

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Восточная Звезда авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Введенкский Бистәсе авыл җирлегенең Восточная Звезда авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020нче елның 10нчы декабренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Восточная Звезда авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 3200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә килешәсезме?:

- балалар мәйданчыгын төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

4. Халык җыенын Восточный Звезда поселогы, Грушевая урамы адресы буенча 10.00 сәгатьтә су башнясы янында үткәрергә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозов